**ГЛАВА**
**Новобизякинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Яңа Бәзәкә авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2019 Яңавыл авылы № 4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Яңа Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы карар бирде:

1. Элеккеге Яңа Бәзәкә мәктәбе бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2019 нчы елның 8 нче ноябренә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Яңа Бәзәкә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-III группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия армиясендә хезмәт итүче затлардан, иректән мәхрүм ителгәннәрдән тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә салым кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы:
1. Яңа Бәзәкә авылының Тукай урамына вак таш җәю.

«ӘЙЕ» «ЮК".

3. Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге Карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

М.М. Ногманов